ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 15 » июнь 2021 ел № 421

**«2021 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлык хәрәкәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2021 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлык хәрәкәтен үстерү» муниципаль программасын расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
15.06. 2021 ел, №121
карарына кушымта

**2021 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлык хәрәкәтен үстерү»**
**муниципаль программасы**

Гомуми нигезләмәләр

Ихтыярыйлык (волонтерлык) - мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, халыкка социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт, әйләнә-тирә мохитне саклау, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү кебек өлкәләрдәге социаль бурычларны хәл итү максатыннан эшләрне һәм (яки) хезмәт күрсәтүләрне түләүсез башкару рәвешендәге эшчәнлек алып бару. Ихтыярый эшчәнлекне (волонтерлык) үстерүгә һәм таратуга ярдәм итү социаль һәм яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренең берсе.

«2021 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлык хәрәкәтен үстерү» муниципаль программасы программаларның методологик бердәмлеген, Арча муниципаль районының социаль үсеш стратегиясе белән яраштыруны тәэмин итәчәк.

Программаның төп максаты-Арча муниципаль районының тармакара характердагы төп социаль проблемаларын хәл итү һәм шул нигездә халыкның тормыш дәрәҗәсен яхшырту, эш белән мәшгуль итү һәм интеллектуаль потенциалын үстерү.

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | «2021 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлык хәрәкәтен үстерү» муниципаль программасы |
| **Программаның муниципаль заказчысы** | Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| **Программаны эшләүче** | Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге (алга таба -ОДМС) |
| **Программаның төп башкаручылары** | - Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>- Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ;<br>- Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ;<br>- Арча муниципаль районының «Финанс- |

| | |
|---|---|
| | бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе;<br>- Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге;<br>-учреждениеләр, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр. |
| **Программаның максаты** | Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче барлык яшьтәге гражданнарны ихтыярыйлык хәрәкәте (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп итү |
| **Программаның бурычлары** | - социаль бурычларны хәл итүдә ихтыярыйлык (волонтерлык) оешмаларына һәм ихтыярыйлык хәрәкәтендә катнашучыларга (волонтерлар) ихтыяҗ булуны тәэмин итә торган шартлар тудыру, шулай ук җәмгыятьтә ихтыярыйлыкны (волонтерлык) тануны арттыру;<br>- ихтыярыйлык хәрәкәте юнәлеше буенча эш тәҗрибәсе туплау һәм тарату;<br>- волонтерлар эшчәнлеге мөмкинлекләре турында киң мәгълүмат бирү, яшьләрне ихтыярыйлык хәрәкәтенә җәлеп итү;<br>- ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегенә методик, мәгълүмати, консультация, белем һәм ресурс ярдәмен үстерү;<br>-районның ихтыярыйлык хәрәкәтен үстерүгә яңа технологияләр кертү;<br>-социаль әһәмиятле проектлар, акцияләр, чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;<br>-оешмаларга, оештыру рәвешләренә бәйсез рәвештә, ихтыярыйлык инициативалары буенча нәтиҗәлерәк эшләүгә ярдәм күрсәтү;<br>- иреклелек хәрәкәтен пропагандалау (реклама агитацияләре, акцияләр уздыру, массакүләм мәгълүмат чараларында (социаль медиа) ихтыярыйлык темасын яктырту;<br>- ихтыярыйлык хәрәкәте (волонтерлык) өлкәсендә иреклелек (волонтер) оешмаларының коммерциячел булмаган секторның башка оешмалары, бизнес, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, массакүләм мәгълүмат чаралары, халыкара, дини һәм башка кызыксынган оешмалар белән хезмәттәшлеген дә кертеп, секторара хезмәттәшлек масштабларын киңәйтү; |

| | |
|---|---|
| | - волонтерлар хәрәкәте эшчәнлеген стимуллаштыру һәм үстерү ысулларын булдыру, ихтыярый катнашучыларның иң яхшыларын бүләкләү. |
| **Программаны гамәлгә ашыру сроклары** | 2021-2024 еллар |
| **Финанслау чыганагы** | - җирле бюджет |
| **Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре** | -Арча муниципаль берәмлеге территориясендә ирекле эшчәнлеккә җәлеп ителгән гражданнар өлешен 2024 елга 9 %ка кадәр арттыру.<br>- 2024 елга кадәр белем алган волонтерлык хәрәкәте координаторлары санын 12 кешегә кадәр арттыру. |
| **Программаны гамәлгә ашыруны тикшереп тору** | Арча муниципаль районы башкарма комитеты |

## 1 бүлек. Проблеманы тасвирлау һәм программаның максатлары

Волонтерлар эшчәнлеге, ихтыярый активлык җәмгыятьнең мәгариф, фән, мәдәният, сәнгать, сәламәтлек саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм башка өлкәләрдә социаль үсешенең мөһим факторлары булып тора.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 17 ноябрендәге 1662-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2020 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең озак срокли социаль-икътисадый үсеш концепциясе нигезендә волонтерлыкны үстерүгә һәм таратуга ярдәм итү социаль һәм яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре исәбенә кертелгән. Ихтыярый эшчәнлек яшьләрнең иҗади инициативасына һәм социаль иҗатына киңлек бирә торган өлкә булып тора, ул яшьләрнең актив гражданлык позициясен тәрбияләү максатларына һәм яшь кешене социаль җаваплы итүгә мөһим өлеш кертә.

Ихтыярыйлык хәрәкәтендә актив шөгыльләнүче халык чаралар һәм акцияләр оештыру, халыкның төрле категорияләре белән аралашу күнекмәләре һәм осталыклары ала, бу аларны хезмәт базарында конкуренциягә сәләтлерәк итә.

Шәхси үсештән тыш, волонтерлар җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүдә актив ярдәм итә, ятим балаларга, ветераннарга ярдәм күрсәтә, балалар һәм яшьләр арасында бәйлелекне профилактикалау белән шөгыльләнә.

Төп максат - җәмгыятьтә ихтыярый (волонтерлык) хезмәт идеяләрен пропагандалау һәм укучыларны һәм студентларны социаль әһәмиятле проблемаларны хәл итүгә җәлеп итү юлы белән халыкның югары әхлакый

сыйфатларын үстерү (социаль, экологик, гуманитар, мәдәни-мәгариф, мәгърифәтчелек һәм башка проектларда һәм программаларда катнашу аша).

### 1.1 Программаның төп бурычлары

1. Ихтыярыйлык (волонтерлык) оешмаларының һәм волонтерларның социаль бурычларны хәл итүдә катнашуына ихтыяҗ булуны тәэмин итә торган шартлар тудыру, шулай ук җәмгыятьтә иреклелекне (волонтерлык) үстерү;
2. Ихтыярыйлык юнәлешләре буенча эш тәҗрибәсе туплау һәм тарату;
3. Волонтерлар эшчәнлеге мөмкинлекләре турында киң мәгълүмат бирү, яшьләрне иреклелек хәрәкәтенә җәлеп итү;
4. Ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлеккә методик, мәгълүмати, консультация, белем бирү һәм ресурс ярдәмен үстерү;
5. Районда ихтыярыйлык хәрәкәтен үстерүдә яңа технологияләр кертү;
6. Төрле социаль әһәмиятле проектлар, акцияләр, чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;
7. Оештыру рәвешләренә бәйсез рәвештә, оешмаларга ихтыярыйлык инициативаларына ярдәм итү буенча нәтиҗәлерәк эшләргә ярдәм итү;
8. Ихтыярыйлык хәрәкәтен пропагандалау (реклама агитацияләре, акцияләр уздыру, массакүләм мәгълүмат чараларында (социаль медиа) иреклеләр темасын яктырту;
9. Ихтыярыйлык (волонтерлык) оешмаларының коммерциячел булмаган секторның башка оешмалары, бизнес, дәүләт хакимияте органнары белән җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, массакүләм мәгълүмат чаралары, халыкара, дини һәм башка кызыксынучы оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген дә кертеп, ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә секторара хезмәттәшлек масштабларын киңәйтү;
10. Волонтерлар хәрәкәте эшчәнлеген стимуллаштыру һәм үстерү ысулларын эшләү, ихтыярый катнашучыларның иң яхшыларын бүләкләү.

## 2 нче бүлек. Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары

Программа 2021-2024 еллар дәвамында ике этапта гамәлгә ашырылачак.

I этап - 2021-2022 ел

II этап - 2023-2024 ел

**Беренче этапта:**

-Программаны гамәлгә ашыруның оештыру нигезләрен эшләү;
- кызыксынучы оешмалар белән элемтәләр урнаштыру;
-оештыручылар, яшьләр волонтерлык хәрәкәтендә катнашучылар өчен методик кулланмалар, мәгълүмати брошюралар эшләү;

**Икенче этапта:**

- төп чаралар планы нигезендә программаның төп чараларын гамәлгә ашыру күздә тотыла.

## 3 бүлек. Программа чаралары исемлеге һәм тасвирламасы

**«2021 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында** ихтыярыйлык **хәрәкәтен үстерү» муниципаль программасының төп чаралар планы**

| № | Чаралар исеме | Үтәү срогы | Җаваплы башкаручылар | Финанслау күләме (мең сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 ел | 2022 ел |
| 1. | Ихтыярыйлык оешмалары җитәкчеләренең муниципаль киңәшмә-семинарлары | Ел дәвамында | ОДМС, “Мәгариф идарәсе” МУ, “Мәдәният идарәсе”, “Җиңү волонтерлары”, социаль яклау бүлеге, Форпост үзәге, 21 гасыр яшьләре, Арча МР ДОСААФ | 0 | 0 |
| 2. | "Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше яклы! Кушылыгыз!» акциясе | Февраль | ОДМС, "Җиңү волонтерлары" | 0 | 0 |
| 3. | Бәйрәмнәргә багышланган «ТатАрча Party» кичке тематик чаралар сериясе | Февраль, Март | АМР башкарма комитеты, 21 гасыр яшьләре, «Мәдәният идарәсе» МУ | 0 | 5 |
| 4. | Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган "Сезнең өчен, кадерле хатын-кызлар" акциясе үткәрү | Март | 21 гасыр яшьләре, «Мәгариф идарәсе» МУ, «Мәдәният идарәсе» МУ | 0 | 3 |
| 5. | Укучы яшьләр арасында спорт ориентлашуы буенча район ярышлары | Март | ОДМС, волонтерлар | 0 | 8 |
| 6. | Язгы/ Көзге игелек атнасы | Март | «Мәгариф идарәсе» МУ | 0 | 0 |
| 7. | «ФОРПОСТ» отрядларында катнашучылар өчен гомуми физик әзерлек буенча ярышлар | Март-апрель | «Мәгариф идарәсе» МУ, Форпост үзәге | 0 | 5 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 8. | «Җиңү агачы» бөтенроссия акциясе | Апрель | Бердәм Россия,<br>«Мәгариф идарәсе» МУ,<br>Ветераннар советы | 0 | 1 |
| 9. | «Георгий тасмасы» бөтенроссия акциясе | Май | 21 гасыр яшьләре,<br>«Мәгариф идарәсе» МУ | 0 | 0 |
| 10. | “Хәрби хезмәткә чакырылу көне” район социаль-патриотик акциясендә катнашу | Апрель, октябрь | Хәрби комиссариат, Арча муниципаль районы ДОСААФ ы, “Мәгариф идарәсе” МУ, КДН. | 0 | 0 |
| 11. | «Үлемсез полк» бөтенроссия акциясе | Май | Арча районы оешмалары | 0 | 0 |
| 12. | "ГТО мәйданчыгы" сәламәтлек фестивале | Февраль Сентябрь | ОДМС, КДН, волонтерлар | 0 | 0 |
| 13. | Яшь оештыручыларны язгы кыр һәм көзге кыр эшләре барышында иң яхшы күрсәткечләр буенча бүләкләү | Май<br>Август | Арча районы УСХиП булеге,<br>ТР АМОның Арча бүлекчәсе | 0 | 25 |
| 14. | СПИДтан үлгәннәрне искә алу көне кысаларында "Мине исеңдә тот" акциясе | Май | Җиңү волонтерлары, 21 гасыр яшьләре, КДН, Арча үзәк район хастаханәсе | 0 | 0 |
| 15. | «Яшьләр тәмәке тартуга каршы. Бөтенләйгә! " акциясе | Май | Волонтерлар,<br>21 гасыр яшьләре,<br>Форпост үзәге | 0 | 0 |
| 16. | Балаларны яклау көненә багышланган балалар Сабантуе | Июнь | КДН, опека һәм попечительлек бүлеге, социаль яклау бүлеге,<br>«Мәгариф идарәсе» МУ | 25 | 13 |
| 17. | Балаларны яклау көненә багышланган “Балаларга ярдәм ит” акциясе | Июнь | МУ «Мәгариф идарәсе», «Җиңү волонтерлары», 21 гасыр яшьләре, социаль яклау бүлеге | 11 | 0 |
| 18. | “Без - Россия гражданнары!” бөтенроссия акциясе | Июнь | Бердәм Россия,<br>Форпост үзәге | 1 | 1 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **19.** | «Хәтер шәме» бөтенроссия акциясе | Июнь | Җиңү волонтерлары | 1 | 0 |
| **20.** | Хәйрия концерты | Июль | Барлык яшьләр оешмалары, “Мәдәният идарәсе” МУ | 8 | 8 |
| **21.** | Өлкәннәр декадасы | Октябрь | Волонтерлар,<br>21 гасыр яшьләре,<br>Социаль яклау бүлеге ,<br>Ветераннар советы | 7 | 0 |
| **22.** | Хокук бозуларны профилактикалау буларак күңелле стартлар | Ноябрь-Декабрь | "Форпост" үзәге, КДН, ОДМС | 3 | 3 |
| **23.** | Инвалидлар декадасы | Декабрь | Волонтерлар, 21 гасыр яшьләре, социаль яклау бүлеге | 1,367 | 1,367 |
| **24.** | Ирекләләр көнен Россия күләмендә бәйрәм итү һәм елга йомгак ясау | Декабрь | Барлык яшьләр оешмалары, «Мәдәният идарәсе» МУ | 17 | 17 |
| **25.** | «Өмет чыганагы» тернәкләндерү үзәгендә булу | Декабрь | 21 гасыр яшьләре,<br>КДН | 5 | 2 |
| **26.** | «Тәмәке, сыра һәм спиртлы эчемлекләр кулланунын зыяны турында» темасына түгәрәк өстәл артында әңгәмә үткәрү | Декабрь | "Форпост" үзәге<br>Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча ЮХИДИ инспекторы | 0 | 0 |
| **27.** | Дан, истәлекле урыннар һәм хәрби җирләү аллеяләрен чистарту | Ел дәвамында | Волонтерлар,<br>21 гасыр яшьләре | 0 | 0 |
| **28.** | Социаль патронатта торучы гаиләләргә адреслы ярдәм | Ел дәвамында | Волонтерлар,<br>21 гасыр яшьләре | 5 | 0 |
| **29.** | Спорт чаралары үткәрү | Ел дәвамында | Барлык яшьләр оешмалары | 43 | 35 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **30.** | "Без имин юлны сайлыйбыз" акциясе үткәрү | Ел дәвамында | Форпост үзәге | 4 | 4 |
| **31.** | Тәмәке тартуны, алкоголизмны һәм наркоманияне профилактикалау чаралары үткәрү | Ел дәвамында | Форпост үзәге | 0 | 0 |

## 4 бүлек. Программа белән идарә итү һәм аны гамәлгә ашыру механизмы

Арча муниципаль районында волонтерлык хәрәкәтен оештыру һәм үстерү өчен өч төп төр форма кулланыла:

1) волонтерларның халыкның социаль якланмаган төркемнәре белән эше:

- ятим балалар, инвалидлар, картлар.

2) граждан-патриотик:

- Бөек Ватан сугышы ветераннарына ярдәм;
- Җиңү көненә багышланган тантаналы чаралар оештыру;

3) сәламәт яшәү рәвеше, тискәре социаль күренешләрне профилактикалау:

- наркоманиягә, тәмәке бәйлелегенә, алкоголизмга, ВИЧ/СПИД таралуга каршы көрәшкә юнәлдерелгән пропаганда акцияләре оештыру;
- донор каны һәм плазма җыю буенча акцияләр оештыру;
- профилактика юнәлешендәге мәдәни һәм массакүләм спорт чаралары оештыру;
- Арча муниципаль районында яшьләрнең ялын оештыру.

4) экологик акцияләр:

- халык күпләп җыела торган территорияләрне җыештыруда ярдәм (парклар, стадионнар, комлык);
- яр буе территориясен җыештыру;
- районның ял итү урыннарын (урман массивы, аланнар) һәм туристлык объектларын җыештыру;

5) «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру:

- федераль проект чараларын гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр белән бергәләп эшләү.

**Программаны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән төп чаралар**

- профилактик чаралар оештыручы волонтерлар өчен өйрәнү семинарлары һәм тренинглары үткәрү;
-волонтерларның слетларда, түгәрәк өстәлләрдә катнашуы;
- район һәм муниципаль чараларда катнашу, шулай ук социаль учреждениеләрдә эшләү.

**Волонтерлар хәрәкәтен үстерү чаралары.**
**Программаның котелгән нәтиҗәләре**

Эшнең төп нәтиҗәсе - эшчәнлек барышында халыкнын җаваплыгын, сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру;

Гражданлык җәмгыяте институтларының социаль әһәмиятле эшчәнлеген активлаштыру, муниципаль ярдәм күрсәтү программасының стимуллаштыру чараларын гамәлгә ашыру юлы белән гражданнарның инициативалары санын арттыру;

Сәламәт яшәү рәвеше буенча акцияләрдә катнашу, җәмгыятьтә зарарлы гадәтләрне һәм асоциаль тәртипләрне массакүләм профилактикалауга ярдәм итү;

- әзерлек һәм квалификация күтәрү узган социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләренең санын һәм вәкилләре укыту чараларында катнашкан коммерциячел булмаган оешмалар санын арттыру;
- иҗтимагый аңның һәм иҗтимагый катнашуның югары дәрәҗәсен формалаштыру;
- коммерциячел булмаган оешмаларның социаль әһәмияте турында халыкның хәбәрдарлык дәрәҗәсен арттыру;
- коммерциячел булмаган оешмаларның уңай имиджын ныгыту;
- җирле үзидарәне гамәлгә ашыруның сыйфатын арттыру.

## 5 бүлек. Программа максатларының индикаторлары

Программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:
- социаль үсеш һәм социаль җаваплылыкта уңай тәҗрибә тупларга;
- яшьләрне дәрестән тыш вакыттагы мәшгульлеген тәэмин итү һәм аларны, барыннан да элек, наркотиклар, исерткеч эчемлекләр куллanудан читләштерергә;
- районның өлкән яшьтәге халкының ялын оештырырга;
- кеше кыйммәтләрен сакларга һәм үстерергә.

## 6 бүлек. Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле ресурслар

Программаны гамәлгә ашыру «2020 - 2022 елларга Арча муниципаль районының яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасы кысаларында җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла һәм 525 468,00 сум тәшкил итә, шул исәптән:

2021 ел - 131 367,00 сум;
2022 ел - 131 367,00 сум;
2023 ел - 131 367,00 сум;
2024 ел - 131 367,00 сум;

Программа чараларын финанслау күләме фаразлау характерында һәм ел саен төгәлләштерелергә тиеш.